**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

07.03.2016

№ 170

**О межведомственной рабочей группе по вопросам профилактики терроризма и экстремизма в Республике Татарстан**

В целях обеспечения взаимодействия органов исполнительной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления в Республике Татарстан, организаций в реализации мероприятий, направленных на профилактику терроризма и экстремизма в Республике Татарстан:

1. Образовать межведомственную рабочую группу по вопросам профилактики терроризма и экстремизма в Республике Татарстан.

2. Утвердить прилагаемые:

а) Положение о межведомственной рабочей группе по вопросам профилактики терроризма и экстремизма в Республике Татарстан;

б) состав межведомственной рабочей группы по вопросам профилактики терроризма и экстремизма в Республике Татарстан.

3. Упразднить межведомственную рабочую группу по вопросам реализации Республиканской целевой программы по профилактике терроризма и экстремизма в Республике Татарстан на 2012-2014 годы.

4. Признать утратившим силу распоряжение Президента Республики Татарстан от 2 марта 2012 года № 120 «О межведомственной рабочей группе по вопросам реализации Республиканской целевой программы по профилактике терроризма и экстремизма в Республике Татарстан на 2012-2014 годы».

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Утверждено
распоряжением Президента
Республики Татарстан

от «07» марта 2016 года

№ 170

**Положение**
**о межведомственной рабочей группе по вопросам профилактики терроризма и экстремизма в Республике Татарстан**

1. Межведомственная рабочая группа по вопросам профилактики терроризма и экстремизма в Республике Татарстан (далее – Рабочая группа) является межведомственным органом, образованным для обеспечения координации действий министерств, ведомств, иных государственных органов, органов местного самоуправления в Республике Татарстан и организаций по реализации мероприятий:

Комплексного плана противодействия идеологии терроризма в Российской Федерации на 2013 – 2018 годы, утвержденного Президентом Российской Федерации 26 апреля 2013 года (№ Пр-1069);

Плана мероприятий по реализации Стратегии противодействия экстремизму в Российской Федерации, утвержденного распоряжением Правительства Российской Федерации от 30 июня 2015 года № 4721п-п44;

Плана мероприятий по обеспечению подготовки специалистов с углубленным знанием истории и культуры ислама в 2014 – 2016 годах, утвержденного распоряжением Правительства Российской Федерации от 14 мая 2014 года № 815-р;

подпрограммы «Профилактика терроризма и экстремизма в Республике Татарстан на 2014 – 2016 годы» государственной программы «Обеспечение общественного порядка и противодействие преступности в Республике Татарстан на 2014 – 2020 годы», утвержденной постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 октября 2013 года № 764;

государственной программы «Реализация государственной национальной политики в Республике Татарстан на 2014 – 2020 годы», утвержденной постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2013 года № 1006.

2. Рабочая группа в своей деятельности руководствуется федеральным законодательством, законодательством Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

Положение о Рабочей группе и ее состав утверждаются Президентом Республики Татарстан.

Общие правила организации работы Рабочей группы устанавливаются

регламентом Рабочей группы, утверждаемым решением Рабочей группы.

3. Рабочая группа может образовывать экспертные группы для обсуждения и решения отдельных вопросов по направлениям своей деятельности.

Состав экспертной группы утверждается руководителем Рабочей группы по представлению членов Рабочей группы.

4. Основными задачами Рабочей группы являются:

проведение комплексного анализа состояния профилактики терроризма и экстремизма с последующей выработкой рекомендаций субъектам профилактики;

своевременное выявление негативных тенденций, прогнозирование развития складывающейся в Республике Татарстан обстановки в сфере противодействия терроризму и экстремизму, разработка и внесение соответствующих предложений;

разработка новых форм и способов профилактики терроризма и экстремизма;

участие в разработке планов мероприятий по профилактике терроризма и экстремизма, подготовке проектов совместных приказов, указаний, информационных писем и иных организационно-распорядительных документов министерств, ведомств и организаций по вопросам совершенствования системы мер по профилактике терроризма и экстремизма;

обеспечение взаимодействия между территориальными органами федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан (далее – территориальные органы федеральных органов исполнительной власти), органами исполнительной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления в Республике Татарстан (далее – органы местного самоуправления), а также организациями по вопросам реализации мероприятий по профилактике терроризма и экстремизма;

разработка проектов долгосрочных республиканских и муниципальных комплексных целевых программ по профилактике терроризма и экстремизма, организация контроля за их выполнением, целевым использованием выделенных денежных средств;

участие в подготовке информационно-аналитических и иных материалов о результатах реализации мероприятий по профилактике терроризма и экстремизма для направления в органы государственной власти Российской Федерации и Республики Татарстан.

5. Рабочая группа для реализации возложенных на нее задач наделяется следующими полномочиями:

сбор сведений о полноте и эффективности реализации мероприятий по профилактике терроризма и экстремизма министерствами, ведомствами, иными государственными органами, органами местного самоуправления и организациями;

представление Президенту Республики Татарстан, Государственному

Совету Республики Татарстан, Кабинету Министров Республики Татарстан, антитеррористической комиссии в Республике Татарстан и органам местного самоуправления информации о состоянии деятельности по профилактике терроризма и экстремизма, внесение предложений по повышению ее эффективности;

оказание методической и практической помощи в организации изучения состояния работы по выполнению требований законодательства в сфере противодействия терроризму и экстремизму в территориальных органах федеральных органов исполнительной власти, органах исполнительной власти Республики Татарстан, органах местного самоуправления, предприятиях и организациях, расположенных на территории Республики Татарстан.

6. Рабочая группа имеет право:

запрашивать в установленном порядке у территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, а также организаций материалы и информацию по вопросам, отнесенным к компетенции Рабочей группы;

приглашать на заседания Рабочей группы представителей территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, а также организаций по вопросам, отнесенным к компетенции Рабочей группы;

вносить должностным лицам предложения по реализации мероприятий по профилактике терроризма и экстремизма;

привлекать в установленном порядке представителей заинтересованных территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов исполнительной власти Республики Татарстан, научных, общественных и других организаций, а также специалистов (экспертов) для проведения консультаций и подготовки предложений по отдельным вопросам, относящимся к деятельности Рабочей группы.

7. Члены Рабочей группы работают на общественных началах. Заседания Рабочей группы проводятся по мере необходимости, но не реже одного раза в квартал. Решения Рабочей группы оформляются протоколом.

8. Возглавляет Рабочую группу руководитель, а в его отсутствие – заместитель по поручению руководителя Рабочей группы.

9. Руководитель Рабочей группы:

осуществляет общее руководство деятельностью Рабочей группы;

ведет заседания и подписывает протоколы заседаний Рабочей группы;

дает поручения членам Рабочей группы по вопросам, отнесенным к ее компетенции;

представляет Рабочую группу по вопросам, отнесенным к ее компетенции.

10. Заместитель руководителя Рабочей группы:

проводит заседания и подписывает протоколы заседаний Рабочей группы в случае отсутствия руководителя Рабочей группы и по его поручению;

дает поручения членам Рабочей группы в пределах своей компетенции;

по поручению руководителя представляет Рабочую группу при взаимодействии с органами государственной власти, органами местного самоуправления, предприятиями и организациями, а также средствами массовой информации;

выполняет иные поручения руководителя Рабочей группы.

11. Ответственный секретарь Рабочей группы:

принимает участие в выполнении плановых мероприятий Рабочей группы;

запрашивает в установленном порядке у территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, а также организаций материалы и информацию по вопросам реализации мероприятий по профилактике терроризма и экстремизма и использованию финансовых средств, выделенных на их реализацию;

осуществляет подготовку и направление ежеквартальных отчетов о реализации мероприятий по профилактике терроризма и экстремизма в Министерство экономики Республики Татарстан;

принимает участие в подготовке информационно-аналитических и иных материалов о реализации мероприятий по профилактике терроризма и экстремизма для направления в органы государственной власти Российской Федерации и Республики Татарстан.

12. Члены Рабочей группы:

принимают участие в выполнении плановых мероприятий Рабочей группы;

принимают участие в подготовке аналитических материалов для направления в органы государственной власти Российской Федерации и Республики Татарстан;

обеспечивают формирование и представление сводного отчета о состоянии работы по реализации мероприятий по профилактике терроризма и экстремизма в соответствующем государственном (муниципальном) органе, организации;

выступают на заседаниях Рабочей группы;

вносят предложения по вопросам, входящим в компетенцию Рабочей группы, в случае необходимости – предложения о проведении голосования по данным вопросам;

принимают участие в голосовании на заседаниях Рабочей группы;

обладают равными правами при подготовке и обсуждении рассматриваемых на заседании Рабочей группы вопросов;

знакомятся с документами и материалами Рабочей группы,

непосредственно касающимися ее деятельности в области противодействия терроризму и экстремизму;

представляют руководителю Рабочей группы кандидатуры членов экспертной группы;

привлекают в установленном порядке по согласованию с руководителем Рабочей группы сотрудников и специалистов организаций к экспертной, аналитической и иной работе, связанной с деятельностью Рабочей группы;

излагают в случае несогласия с решением Рабочей группы в письменной форме свое особое мнение, которое подлежит отражению в протоколе заседания Рабочей группы и приобщению к нему.

Член Рабочей группы обязан:

организовывать подготовку вопросов, вносимых на рассмотрение Рабочей группы в соответствии с решениями Рабочей группы, руководителя Рабочей группы или по предложениям членов Рабочей группы, утвержденным протокольным решением, обеспечивать контроль за их исполнением;

присутствовать на заседаниях Рабочей группы. В случае невозможности присутствия члена Рабочей группы на заседании он обязан заблаговременно известить об этом руководителя Рабочей группы или лицо, исполняющее его обязанности;

организовывать в рамках своих должностных полномочий выполнение решений Рабочей группы;

выполнять требования регламента Рабочей группы, устанавливающего общие правила организации работы Рабочей группы.

13. Доступ средств массовой информации к сведениям о деятельности Рабочей группы и порядок размещения в информационных системах общего пользования сведений о вопросах и материалах, рассматриваемых на заседаниях Рабочей группы, определяются законодательством о порядке освещения в средствах массовой информации деятельности органов государственной власти.

14. Решение об упразднении Рабочей группы принимает Президент Республики Татарстан.

Утвержден
распоряжением Президента
Республики Татарстан

от «07» марта 2016 года

№ 170

**Состав**
**межведомственной рабочей группы по вопросам профилактики терроризма и экстремизма в Республике Татарстан**

| | |
|---|---|
| Шафигуллин Айрат Радинович | Секретарь Совета Безопасности Республики Татарстан, руководитель межведомственной рабочей группы |
| Шайхразиев Василь Габтелгаязович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, заместитель руководителя межведомственной рабочей группы |
| Галиев Ильдар Шамилевич | заведующий отделом по обеспечению деятельности Совета Безопасности Республики Татарстан, секретарь межведомственной рабочей группы |
| Ахметова Эльвира Фанисовна | заместитель руководителя Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» |
| Барышев Александр Георгиевич | исполнительный секретарь Совета муниципальных образований Республики Татарстан (по согласованию) |
| Гильманов Рафаиль Валиевич | заместитель Министра внутренних дел по Республике Татарстан – начальник полиции (по согласованию) |
| Гафаров Марат Ринатович | первый заместитель министра труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан |
| Гарифуллин Рустам Маратович | заместитель министра по делам молодежи и спорту Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Зиннуров Фоат Канафиевич | председатель межвузовского Комитета по профилактике экстремизма, предотвращению межнациональных конфликтов среди студентов вузов Республики Татарстан, начальник Казанского юридического института Министерства внутренних дел Российской Федерации (по согласованию) |
| Мингулов Алмаз Минвазыхович | заместитель министра по делам молодежи и спорту Республики Татарстан |
| Мухарлямов Руслан Робертович | заместитель руководителя Департамента Президента Республики Татарстан по вопросам внутренней политики |
| Нигматуллина Гузель Азатовна | заместитель министра культуры Республики Татарстан |
| Поминов Андрей Иванович | первый заместитель министра образования и науки Республики Татарстан |
| Фомин Анатолий Алексеевич | председатель Общественной палаты Республики Татарстан (по согласованию) |
| Файзрахманов Марат Джаудатович | первый заместитель министра финансов Республики Татарстан – директор Департамента казначейства Министерства финансов Республики Татарстан |
| Хиалеев Эдуард Данилович | заместитель начальника Управления Федеральной службы исполнения наказаний по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Щелоков Сергей Юрьевич | заместитель начальника Управления Федеральной службы безопасности Российской Федерации по Республике Татарстан (по согласованию) |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

07.03.2016

№ 170

**Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме турында**

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, оешмаларның Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруда үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында:

1. Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркемен төзергә.

2. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:
а) Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме турында нигезләмәне;
б) Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме составын.

3. 2012-2014 елларга Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча республика максатчан программасын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркемен таратырга.

4. Татарстан Республикасы Президентының «2012-2014 елларга Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча республика максатчан программасын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2012 елның 2 мартындагы 120 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның « 07 » мартындагы
170 номерлы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – Эш төркеме) министрлыклар, ведомстволар, башка дәүләт органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру буенча килештерелгән гамәлләрен координацияләүне тәэмин итү өчен оештырылган ведомствоара орган булып тора:

Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2013 елның 26 апрелендә расланган (№ Пр-1069) 2013 – 2018 елларга Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы көрәшүнең комплекслы планы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 30 июнендәге 4721п-п44 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә экстремизмга каршы көрәшү стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 14 маендагы 815-р номерлы карары белән расланган 2014 – 2016 елларда ислам тарихын һәм мәдәниятен тирәнтен үзләштергән белгечләрне әзерләүне тәэмин итү чаралары планы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшү» дәүләт программасына «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» өстәмә программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы.

2. Эш төркеме үзенең эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы Законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

Эш төркеме турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана. Эш төркеме эшчәнлеген

оештыруның төп кагыйдәләре Эш төркеме карары белән раслана торган Эш төркеме регламентында билгеләнә.

3. Эш төркеме үз эшчәнлеге юнәлешләренә кагылышлы аерым мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм аларны хәл итү өчен эксперт төркемнәре оештырырга мөмкин.

Эксперт төркеме составы Эш төркеме әгъзалары тәкъдиме буенча Эш төркеме җитәкчесе тарафыннан раслана.

4. Эш төркеменең төп бурычлары түбәндәгеләр:

терроpчылык һәм экстремистлыкны профилактикалау торышына комплекслы анализ ясап, профилактика субъектларына тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасында террорчылык һәм экстремистлыкка каршы көрәшү өлкәсендәге хәлнең тискәре тенденцияләрен вакытында ачыклау, фаразлау, тиешле тәкъдимнәр эшләү һәм кертү;

террорчылык һәм экстремистлыкны профилактикалауның яңа формаларын һәм ысулларын эшләү;

башкаручыларның террорчылык һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча чараларның уртак планын, террорчылык һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча системалы чараларны камилләштерү мәсьәләләре буенча министрлыклар, ведомстволар һәм оешмаларның уртак боерыклары, күрсәтмәләре, мәгълүмати хатлары һәм башка оештыру-боеру документлары проектларын әзерләүдә катнашу;

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары (алга таба – федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), шулай ук оешмалар арасында террорчылык һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча чараларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү;

террорчылык һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча озак вакытка исәпләнгән республика һәм муниципаль комплекслы максатчан программалар проектларын эшләү, аларның үтәлешенә, бүлеп бирелгән акчаның максатчан файдаланылуына контрольне оештыру;

террорчылык һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча чараларны гамәлгә ашыру йомгаклары турында мәгълүмати-аналитик һәм башка материалларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына җибәрү өчен әзерләүдә катнашу.

5. Үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен Эш төркеменә түбәндәге вәкаләтләр бирелә:

министрлыклар, ведомстволар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар тарафыннан террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыруның тулы күләмдә башкарылуы һәм нәтиҗәлелеге турында мәгълүматлар туплау;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан

Республикасында террорчылыкка каршы комиссия һәм җирле үзидарә органнарына террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау эшчәнлегенең торышы турында мәгълүмат бирү, аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр кертү;

федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарында, җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан предприятиеләр һәм оешмаларда террорчылыкка һәм экстремистлыкка каршы көрәшү өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәү эше торышын тикшерүне оештыруда методик һәм гамәли ярдәм күрсәтү.

6. Эш төркеме түбәндәгеләргә хокуклы:

билгеләнгән тәртиптә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан Эш төркеме компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча материаллар һәм мәгълүмат соратырга;

федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар вәкилләрен Эш төркеме компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Эш төркеме утырышларына чакырырга;

вазыйфаи затларга террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча чараларны тормышка ашыру буенча тәкъдимнәр кертергә;

Эш төркеме эшчәнлегенә караган аерым мәсьәләләр буенча консультацияләр уздыру һәм тәкъдимнәр әзерләү өчен федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, фәнни, җәмәгать һәм башка кызыксынган оешмалар вәкилләрен, шулай ук белгечләрне (экспертларны) җәлеп итәргә.

7. Эш төркеме әгъзалары җәмәгать башлангычларында эшли. Эш төркеме утырышлары кирәк булган саен, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Эш төркеме карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

8. Эш төркеменә җитәкче, ә ул булмаганда, Эш төркеме җитәкчесе кушуы буенча аның урынбасары идарә итә.

9. Эш төркеме җитәкчесе:

Эш төркеме эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне тормышка ашыра;

Эш төркеме утырышларын алып бара һәм утырыш беркетмәләренә кул куя;

Эш төркеме компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча аның әгъзаларына күрсәтмәләр бирә;

Эш төркеме компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Эш төркеме вәкиле була.

10. Эш төркеме җитәкчесе урынбасары:

Эш төркеме җитәкчесе булмаган очракта, аның кушуы буенча Эш төркеме утырышларын уздыра һәм утырыш беркетмәләренә кул куя;

үз компетенцияләре чикләрендә Эш төркеме әгъзаларына күрсәтмәләр бирә;

Эш төркеме җитәкчесе кушуы буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр һәм оешмалар, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек иткәндә Эш төркеме вәкиле була;

Эш төркеме җитәкчесенең башка күрсәтмәләрен үти.

11. Эш төркеменең җаваплы секретаре:

Эш төркеменең план чараларын үтәүдә катнаша;

билгеләнгән тәртиптә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау чараларын тормышка ашыру мәсьәләләре һәм аларны үтәү өчен бүлеп бирелгән финанс чыгымнарын файдалану буенча материаллар һәм мәгълүмат соратырга;

террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау чараларын тормышка ашыру турында квартал саен бирелә торган хисапларны әзерләүне һәм аларны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрүне гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына җибәрү өчен террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау чараларын тормышка ашыру турында мәгълүмати-аналитик һәм башка материалларны әзерләүдә катнаша.

12. Эш төркеме әгъзалары:

Эш төркеменең план чараларын үтәүдә катнашалар;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына җибәрү өчен аналитик материаллар әзерләүдә катнашалар;

тиешле дәүләт (муниципаль) органында, оешмада террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау чараларын тормышка ашыруның торышы буенча җыелма хисап формалаштыруны һәм аны тапшыруны тәэмин итәләр;

Эш төркеме утырышларында чыгыш ясыйлар;

Эш төркеме компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр, кирәк булганда, әлеге мәсьәләләр буенча тавыш бирү уздыру турында тәкъдим кертәләр;

Эш төркеме утырышларында тавыш бирүдә катнашалар;

Эш төркеме утырышларында каралган мәсьәләләрне әзерләү һәм алар буенча фикер алышуда тигез хокукка ия булалар;

террорчылыкка һәм экстремистлыкка каршы көрәшү өлкәсендә турыдан-туры Эш төркеме эшчәнлегенә караган документлар һәм материаллар белән танышалар;

Эш төркеме җитәкчесенә эксперт төркеме әгъзаларына кандидатуралар тәкъдим итәләр;

Эш төркеме җитәкчесе белән килештереп, билгеләнгән тәртиптә оешма хезмәткәрләрен һәм белгечләрен Эш төркеме эшчәнлеге белән бәйле эксперт, аналитика һәм башка эшкә җәлеп итәләр;

Эш төркеме карары белән килешмәгән очракта, Эш төркеме утырышы беркетмәсенә кертелергә һәм аңа теркәлергә тиешле үзенең аерым фикерен язмача рәвештә белдерәләр.

Эш төркеме әгъзасы түбәндәгеләргә бурычлы:

Эш төркеме, Эш төркеме җитәкчесе карары яисә Эш төркеме әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә Эш төркеме каравына кертелә торган, беркетмә карары белән расланган мәсьәләләрне әзерләүне оештырырга, аларны үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

Эш төркеме утырышларында катнашырга. Эш төркеме әгъзасының утырышта катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, ул бу турыда алдан ук Эш төркеме җитәкчесенә яисә аның вазыйфаларын башкаручыга хәбәр итәргә тиеш;

үз вазыйфаи вәкаләтләре чикләрендә Эш төркеме карарларын үтәүне оештырырга;

Эш төркеме эшчәнлеген оештыруның гомуми кагыйдәләрен билгеләүче Эш төркеме Регламенты таләпләрен үтәргә.

13. Эш төркеме эшчәнлеге турында мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларында файдалану һәм Эш төркеме утырышларында каралган мәсьәләләр һәм материаллар турында мәгълүматларны гомуми кулланылыштагы мәгълүмат системаларында бастыру тәртибе дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту тәртибе турында законнар нигезендә билгеләнә.

14. Эш төркемен тарату турында карар Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кабул ителә.

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның «07» мартындагы
170 номерлы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме составы**

| | |
|---|---|
| Шәфигуллин<br>Айрат Радин улы | Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре, ведомствоара эш төркеме җитәкчесе |
| Шәйхразиев<br>Васил Габделгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, ведомствоара эш төркеме җитәкчесе урынбасары |
| Галиев<br>Илдар Шамил улы | Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире, ведомствоара эш төркеме секретаре |
| Әхмәтова<br>Эльвира Фәнис кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары |
| Барышев<br>Александр Георгиевич | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Гыйльманов<br>Рафаил Вәли улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры урынбасары – полиция башлыгы (килешү буенча) |
| Гаффаров<br>Марат Ринат улы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары |
| Гарифуллин<br>Рөстәм Марат улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Зиннуров<br>Фоат Канәфи улы | Экстремистлыкны профилактикалау, Татарстан Республикасы югары уку йортлары студентлары арасында милләтара низагларны булдырмау буенча вузара комитет рәисе, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты башлыгы (килешү буенча) |
| Минголов<br>Алмаз Минвазыйх улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары |
| Мөхәрләмов<br>Руслан Роберт улы | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары |
| Нигъмәтуллина<br>Гүзәл Азат кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары |
| Поминов<br>Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары |
| Фомин<br>Анатолий Алексеевич | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Фәйзрахманов<br>Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры |
| Хәялиев<br>Эдуард Данил улы | Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Щелоков<br>Сергей Юрьевич | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |

________